**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**27.05.2019**

______________________ г.Казань № **162**

Татарстан Республикасы спорт министрлыгының «Татарстан Республикасы спорт министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 500 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы спорт министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы спорт министрлыгының «Татарстан Республикасы спорт министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 500 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы спорт министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә түзеп тормаучанлыкны формалаштыру.»;

5.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен башка белгечләр чакырылырга мөмкин.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Мингуловка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов